# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**25 нче октябрь, 2019** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 21 октябрендә 13 сәгатьтә, 2019 елның 23 октябрендә 15 сәгатьтә 30 минутта, 2019 елның 25 октябрендә 18 сәгатьтә, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:
-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;
б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру;
- Мөрәле авылында су насосын алыштыру , моның өчен материаллар сатып алу;
- Мөрәле авылында янгын гидрантларын урнаштыру , моның өчен материаллар сатып алу;
в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Мөрәле авылында юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 341 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -182, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 182 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б) жирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру

- Мөрәле авылында су насосын алыштыру , моның өчен материаллар сатып алу;

- Мөрәле авылында янгын гидрантларын урнаштыру , моның өчен материаллар сатып алу;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Мөрәле авылында юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Зиннатуллин